«Рассмотрено»
Руководитель ШМО
____/З.Ф.Нигматуллина/

Протокол №1 от
« 31 » августа 2023 г.

«Согласовано»
Заместитель
директора по УР
МБОУ «Васильевская
СОШ № 3 ЗМР РТ»
____/Ф.Г.Садриева/
«31» августа 2023 г.

«Утверждаю»
Директор МБОУ
«Васильевская СОШ № 3
ЗМР РТ»
____/М.А.Халиуллина/
Приказ №99-ОД от
« 31» августа 2023 г.

**Рабочая программа**
учебного предмета
родная (татарская) литература 11 класс
Гатиятуллина Марата Гумаровича
учителя татарского языка и литературы
МБОУ «Васильевская средняя общеобразовательная школа №3 ЗМР РТ»

Рассмотрено на заседании
педагогического совета
протокол № 1
от « 31 » августа 2023 г.

## Аңлатма язуы

11 нче сыйныфта татар әдәбиятыннан белем бирүнең **максаты:**татар әдәбиятының барышын, аның аерым чорлардагы торышын, чор әдәбиятының йөзен билгеләүче язучылар иҗатын анализларга һәм бәяләргә өйрәтү тәшкил итә.

**Бурычлар:**

- укучыларда татар әдәбиятының тарихи барышы турында гомуми караш булдыру;
- әдәби-теоретик белемнәр нигезендә әдәби әсәрнең, язучы иҗатының, чор әдәбиятының, гомумән, татар әдәбиятының үзенчәлекләрен табарга, аңларга, бәяләргә күнектерү;
- иҗади фикерләүдәге уртак һәм милли үзенчәлекләрне танырга өйрәтү;
- матур әдәбиятта халык тарихы, милләт язмышы гәүдәләнешенә укучыларның игътибарын туплау, укучыларда кешелеклелек, горурлык, үз кадереңне белү хисләрен тәрбияләү;
- заман таләпләренә җавап бирүче, үз-үзен камилләштерү өстендә даими эшләүче, татар әдәбиятын, мәдәниятен, традицияләрен хөрмәт итүче, татар дөньясына, әдәбиятына кагылышлы бәхәсләрдә катнашып, үз фикерен дәлилле алучы, гуманлы, рухи, әхлакый бай шәхес тәрбияләү.

## Программаның эчтәлеге

### XX гасыр әдәбияты

1. **Сугыш чоры мәдәниятеһәм әдәбияты– 12 сәгать.**

Бөек Ватан сугышы, аның әдәбиятка тәэсире. Төп тема-проблемалар. Әдип һәм җәмгыять мөнәсәбәте.<u>Әдәбият теориясе.</u> Чор стиле.

**М.Җәлил**нең тормыш һәм иҗат юлы. Шагыйрьнең сугыш чоры һәм тоткынлык иҗаты. “Моабит дәфтәрләре” циклы. Шигырьләре: “Хуш, акыллым”, “Окоптан хат”, “Кыз үлеме”, “Кичер, илем”, “Кошчык”, “Шагыйрь”, “Дару”, “Бүреләр”, “Төрмәдә төш”, “Юллар”, “Күлмәк”, “Дуска”, “Тау елгасы”, “Сөю”, “Кар кызы”, “Бер үгет”, “Имән”, “Батырлык турында”.Дошманга нәфрәтнең чагылышы. “Моабит дәфтәрләре”ндәге юмор үзенчәлеге.

**Ф.Кәрим**нең тормыш һәм иҗат юлы. Сугыш чоры шигъриятендә җиңүгә өмет һәм ныклы ышаныч, үлем һәм яшәү фәлсәфәсе. “Шомырт куагы”, “Кала яшьлек”, “Кайгы” шигырьләре.<u>Әдәбият теориясе.</u> Тезмә һәм чәчмә сөйләм үзенчәлекләре. Ритм һәм рифма, тезмә, строфа.

**Ә. Еники**. Тәрҗемәи хәле һәм иҗаты белән таныштыру. “Ана һәм кыз”, “Бер генә сәгатькә” хикәяләрендә сугыш авырлыклары чагылу.

**Ф.Хөсни**нең тормыш һәм иҗат юлы. “Йөзек кашы” повестенда лирик якты хисләрнең тасвирлануы, мәхәббәтнең үкенечле соңы.

“Йөзек кашы” әсәрендә Айдар холкының үзенчәлекләре. Повестьның истәлеккә корылган булуы. Әдәбият теориясе.Язучы стиле: көлке, тәнкыйди, фаҗигале, экзистенциаль, публицистик һ.б. башлангычлар.

2. **Сугыштан соңгы чор мәдәниятеhәм әдәбияты(1950–1960 нчы еллар) – 7 сәгать.**

ХХ гасырның икенче яртысында “Хрущев җепшеклеге” исемен алган ярымдемократик үзгәрешләрнең сүз сәнгатенә уңай йогынтысы. 1950-1970 нче еллар әдәбиятында илдәге һәм республикадагы хәлләрнең чагылуы. Бу чорда татар әдәбиятының төп көчләре һәм аларның әсәрләре турында мәгълүмат бирү. И.Газинең “Онытылмас еллар” трилогиясе турында белешмә бирү. М.Әмирнең “Ялантау кешеләре”, “Саф күңел” диологиясендә сугыш чоры, сугыштан соңгы халык тормышы чагылу.Г.Бәшировның тормыш юлы, иҗаты. “Намус” романы.

**Х.Туфан**ның тоткынлык чор иҗаты. Шигырьләрендә моң-зар, хәсрәт-сагыну, фаҗига хисләренең яңа төсмерләр алуы. “Ә үткәнгә хатлар бармыйлар”, “Иртә төшкән кар”, “Иртәләр җитте исә” шигырьләре.Әдәбият теориясе.Әдәби алымнар: кабатлау, янәшәлек, каршы кую, үткәнгә әйләнеп кайту (ретроспекция).

“Агыла да болыт агыла”, “Сиңа” шигырьләрен уку, анализлау. Авторның татар шигырь төзелешенә алып килгән яңалыгы. Әдәбият теориясе. Тел–стиль чаралары (лексик, стилистик, фонетик чаралар һәм троплар).

**Х.Вахит**ның тормыш юлы һәм иҗаты. “Беренче мәхәббәт” драмасын өйрәнү.

“Беренче мәхәббәт” драмасында гаилә һәм мәхәббәт өчен җаваплылык мәсьәләләренең үзенчәлекле бирелеше.

3. **1960–80нче еллар мәдәниятеhәм әдәбияты– 31 сәгать.**

Татар әдәбиятының милли нигезләргә кайтуы. Шушы чорда яңа жанрларның, тема-мотивлар, әдәби формаларның аваз салуы. Әдәбиятның яңалыкка омтылышы: яңа иҗади агымнарга, жанр формаларына, темаларга мөрәҗәгать итү, әдәби герой мәсьәләсендә эзләнүләр. Традицияләрнең яңаруы, яңа җәмгыять сыйфатларын эзләү, яңа герой. «Авыл прозасы». Ватан, ил, халык образларының эпик гәүдәләнеше; шәхес һәм җәмгыять мөнәсәбәтләре, гражданлык хисе, халыклар язмышы, кешенең рухи дөньясы, чор кыйммәтләре турында уйлану. Азатлык, шәхес иреге, фикер хөрлеге мәсьәләләренең куелышы. Романтизм юнәлешенең яңадан тергезелүе. 1917 еллар инкыйлабына, яңадан төзелгән тормышка бәянең үзгәреш кичерүе. Сугыш темасының үзгә яссылыкта куелышы.

Ә.Еники, С.Хәким, А.Гыйләҗев, Г.Ахунов, М.Мәһдиев иҗаты.

**Әмирхан Еники**нең тормыш юлы, иҗаты. “Төнге тамчылар” хикәясендә психологик анализ алымнары.Әдәбият теориясе. Әсәрдә сурәтләнгән дөнья. Пейзаж, портрет. Психологизм.

**Дәрестән тыш уку.**Ә.Еники. “Гөләндәм туташ хатирәсе” әсәрендә яшьләр арасындагы матур мөнәсәбәтләр, киләчәгең өчен җаваплылык мәсьәләләре.

**Мөхәммәт Мәһдиев**әсәрләре турында мәгълүмат. Аларда сугыш алды, сугыш һәм сугыштан соңгы елларда татар авылы тормышын чагылдыру. “Кеше китә- җыры кала” әсәрендә халкыбызның яшәү рәвеше.Әдәбият теориясе. Әдәбиятның иҗтимагый вазифасы турында белемнәрне ныгыту.

**Дәрестән тыш уку.** М.Мәһдиевнең “Торналар төшкән җирдә” повесте. Әсәрдә татар авылы тормышын сурәтләү үзенчәлекләре.

**С.Хәким**нең тормыш юлы, иҗаты. “Башка берни дә кирәкми”, “Сусау” шигырьләрен уку һәм анализлау.Әдәбият теориясе. Шигырь төзелеше.

**Аяз Гыйләҗев**иҗатына кыскача күзәтү. Проза һәм драма әсәрләрендә психологизм. Язучының кешене шәхес итеп күрергә, шәхес мәнфәгатьләрен алга чыгарып сурәтләргә омтылышы. Кеше һәм җәмгыять мөнәсәбәтләрен тасвирлауда язучы иҗатында үсеш-үзгәрешләр. “Өч аршын җир” повестенда Мирвәли язмышы. Әсәрдәге киеренке конфликт, аның үстерелеше, чынбарлыкның катлаулы яклары геройның эчке дөньясы аша чагылу. Әдәбият теориясе. Әдәби әсәрдә урын һәм вакыт, хронотоп.

**Дәрестән тыш уку.**А.Гыйләҗевнең “Әтәч менгән читәнгә” повестенда образ-характерлар иҗат итү үзенчәлекләре. Әдәбият теориясе.Композиция: тышкы һәм эчке корылыш.

**Гариф Ахунов**иҗатына кыскача күзәтү ясау. “Идел кызы” романы – ике китаптан торган, катлаулы чор һәм язмышларны чагылдырган әсәр. Анда инкыйлаб һәм шәхес язмышы мәсьәләсе.

“Идел кызы” романында Габбас мулланың бай һәм каршылыклы рухи дөньясы. Әдәбият теориясе.Тема, проблема, идея, пафос. Идеал.

**Әхсән Баянов**ның тормыш юлы һәм иҗаты. Шигырь һәм поэмалары, аларны “фикер поэзиясенә” кертә торган сыйфатлар. “Сәяхәтнамә” поэмасына анализ. Кеше һәм табигатьне фәлсәфи тирәнлек белән сурәтләү.Әдәбият теориясе. Лиро-эпик жанрлар: сюжетлы шигырь, мәсәл, баллада, нәсер, поэма.Поэма жанрының төрләре: романтик поэма, реалистик поэма.

**Дәрестән тыш уку.**Әхсән Баянов. “Тау ягы повесте”.Әдәбият теориясе. Эпиграф, багышлау, көчле позиция.

**4. 1980–2000нче еллар мәдәнияте һәм әдәбияты– 38 сәгать.**

XX-XXI гасыр чигендә татар әдәбиятының тагын бер тапкыр үзгәрүе, яңа дулкын булып күтәрелүе. Үзгәрешләрнең XX гасыр башы татар әдәбиятындагы эзләнүләргә аваздаш булуы. Реализмның типиклаштыруны иҗтимагый–сыйнфый баскычтан гомумкешелек югарылыгына күтәрүе. Совет һәм постсовет заманына тәнкыйди бәя биргән, шәхес һәм җәмгыять каршылыгы ноктасыннан, ил тарихындагы олы этапларның сурәтен тудырган әсәрләр язылу.

И.Салахов, Ф.Бәйрәмова, М.Хәбибуллин, Т.Миңнуллин, И.Юзеев, Г.Афзал, Р.Фәйзуллин, Р.Миңнуллин, М.Әгъләмов, Зөлфәт, Р.Харислар иҗаты.

**И.Салахов**ның тормыш юлы, иҗаты. “Колыма хикәяләре” романы(өзекләр). Романның шәхес культының халыкка алып килгән фаҗигасен бөтен тулылыгы белән күрсәткән әсәр буларак әһәмияте. “Колыма хикәяләре”ндә җәмгыять һәм шәхес мөнәсәбәте проблемасы.

**Ф.Бәйрәмова**ның тормыш һәм иҗат юлы. “Канатсыз акчарлаклар” повестен уку, фикер алышу.“Канатсыз акчарлаклар” повестенда хатын-кызның күңел дөньясын сурәтләү үзенчәлекләре, әсәрнең психологизмы.

**Н.Гыйматдинова**ның тормыш юлы һәм иҗаты турында белешмә. “Сихерче”повестена анализ.Әсәрнең идея-эчтәлеге, образларның бирелеше. Әсәрнең татар әдәбиятына алып килгән яңалыгы. Әдәбият теориясе. Мифологик образ, архетип.

**Дәрестән тыш уку.** Р.Мөхәммәдиев. “Ак кыялар турында хыял”. Әдәбият теориясе.Лирик чигенешләр. Сәнгатьчә дөреслек категориясе.

**М.Хәбибуллин**ның “Кубрат хан” романында (өзекләр) гомумкешелек кыйммәтләренә игътибар, аларны ил мәнфәгатьләре яктылыгында карау, илнең иминлеген, милләт язмышын алга чыгарып тасвирлау. Сюжет җанлылыгы, образлары.

**Туфан Миңнуллин**ның тормыш юлы һәм иҗаты. “Эзләдем, бәгърем, сине” драмасында рухи ныклык, үз бәхетең өчен көрәшүнең әһәмиятен күрсәтү.
**Дәрестән тыш уку.**Т.Миңнуллинның “Саташу” драмасы. Татар театр сәнгатен үстерүдә Т.Миңнуллин драматургиясенең роле.

**И.Юзеев**ның тормыш юлы һәм иҗат үзенчәлекләре. “Гашыйклар тавы” драмасы (1985-1986) – романтик мәхәббәт фаҗигасенә корылган әсәр. “Гашыйклар тавы” әсәрендә кеше һәм табигать, мәхәббәт һәм хыянәт проблемалары.
**Дәрестән тыш уку.**Р.Батулла. “Кичер мине, әнкәй” мелодрамасы.

**Хәзерге татар поэзиясе**, яңа иҗат көчләренең килүе, яңа тема һәм идеяләр.**Р.Фәйзуллинның**иҗатына кыскача күзәтү. Кешенең рухи халәтен, күңел тибрәнешләрен кыска, җыйнак итеп сурәтләүдә шагыйрьнең табыш һәм ачышлары. Психологик киеренкелеккә омтылышы, чичәнлек традицияләрен уңышлы үстерүе. “Нюанслар илендә” циклына керүче шигырҗләрен уку һәм анализлау.

**Р.Миңнуллин**ның тормыш юлы һәм иҗаты. “Татарларым” поэмасында татарның бөек үткәне белән горурлану, бүгенге асылын ачып бирергә тырышу, милләтнең киләчәге турында әрнүле уйланулар.

**Гамил Афзал**ның тормыш юлы, иҗаты. “Язмышлар”, “Чабаклар йөзгән Иделдә”, “Елмаям уйчан гына”, “Бигрәк юаш басып йөрдем җиргә” шигырьләрен уку һәм фикер алышу.Әдәбият теориясе.Көлке: юмор, сатира, сарказм, шарж.

**М.Әгъләмов** иҗаты. Шигъриятенең табигыйлеге. Классик формалардан оста файдалануы. Туган ил, халык һәм милләт язмышы турында фәлсәфи гомумиләштерүләргә ирешүе, халыкчан, җанлы, сәнгатьле фикерләү байлыгыннан тел-стиль сурәтләре алуы. “Кичер!”, “Дәвам” шигырьләренең фикри һәм сәнгатьчә яңалыгы.

**Зөлфәт** иҗатына күзәтү. Шигъри сүзнең эчке куәтен, егәрен арттыруда уңышлары. “Баш очында”, “Дүрт җыр”, “Тамыр көлләре”, “Тойгыларда алтын яфрак шавы” шигырьләрен уку һәм анализлау.

**Р.Харис** поэзиясе турында мәгълүмат. Шигъриятендә заманчалык рухы, фикер тирәнлегенә омтылыш, шагыйрьнең сәнгатьчә үтемле мөмкинлекләр эзләве. Шигырь-поэмаларында милләтнең тарихи үткәне, үткәннең һәм бүгенгенең бәйләнеш-мөнәсәбәте, кешенең тормыштагы һәм җәмгыятьтәге урыны һ.б. фәлсәфи фикерләрнең киң чагылуы. “Тукайның мәхәббәт төшләре” поэмасын уку һәм анализлау.

**5. 2000—2010нчы еллар мәдәнияте һәм әдәбияты – 10 сәгать.**

Психологик башлангычның алга чыгуы аша шәхес тормышы, эчке дөньясының тарихи–иҗтимагый чынбарлыктан өстен булуын раслау. Кешенең аңында, аң төпкелендә барган процессларны тергезү. Мифологик, шартлы–символик образларның активлашуы ярдәмендә милли проблематиканы яңа яссылыкта кую, миллилекне тоталитар идеологиягә каршы торучы көч итеп күтәрү.

**М. Кәбиров**ның тормыш юлы һәм иҗатына күзәтү. “Мәхәббәттән җырлар кала” повестен уку һәм анализлау. Повестьның идея-эстетик эчтәлеге.

**Р. Зәйдулла**ның шигърияте — уйлы-фикерле, фәлсәфи-публицистик яңгырашлы шигърият. Шагыйрьнең тормыш үзгәрешләренә сизгерлеге, бүгенгене халыкның, милләтнең тарихи үткәне белән тыгыз бәйләнештә үзенең дөньяга карашын, уй-фикерләрен поэтик образларда риторикасыз, ихлас күңел айнарлыгы белән гәүдәләндерергә омтылуы. Иҗатында газиз халкыбызның язмышы хакында уйланулар, ихлас мәхәббәт хисләре, хушлашу сагышы һәм киләсе көнгә өмет... “Без очарга әзерләнгән идек”, “Соңару”, “Буран” шигырьләре, аларның үзенчәлекле яклары.

**Зөлфәт Хәким**— татар халкының мәшһүр җырчысы, композитор, драматург, җәмәгать эшлеклесе. З. Хәкимнең тормыш юлы һәм иҗатына күзәтү. “Гасыр моңы” драмасын уку, анализлау. Драманың идея-проблематикасы, образлар системасы.

6. **Дөнья әдәбиятының барышы. Татар, рус һәм чит ил әдәбиятлары арасында күптөрле бәйләнешләр. Мәңгелек темалар һәм образлар – 2 сәг.**

Татар әдәбияты узган юл. Халыкның рухи хәзинәсен саклау һәм үстерүдә татар әдәбиятының роле. Татар балалар әдәбияты. Әдәби процессның юлдашы буларак тәнкыйть.

7. **Тест ярдәмендә татар әдәбиятыннан белем сыйфатын тикшерү. Йомгаклау – 6 сәгать.**

Тест формасында йомгаклау контроль эше.
Тестка нәтиҗә ясау. Ел дәвамында өйрәнгәннәргә йомгак.

Укучыларның белем сыйфатын тикшерү һәм бәяләү, сөйләм телен камилләштерү максатыннан, уку елы дәвамында сыйныфтан тыш уку дәресләре (7 сәгать), тестлар, бәйләнешле сөйләм телен үстерү дәресләре(<u>11 сәгать)</u>үткәрү планлаштырыла.

<u>**Бәйләнешле сөйләм телен үстерү сәгатьләренең бүленеше (11 сәгать):**</u>

- Тулы күләмле 5 сочинение язу (2 се контроль) – 7 сәгать.
- Сочинение язуга әзерлек: план төзү, эпиграф сайлау, материал туплау – 1 сәг.
- Төрле жанрдагы әсәрләрне сәнгатьле сөйләргә өйрәнү күнегүләре. М.Җәлилнең “Кичер, илем” шигырен сәнгатьле итеп яттан сөйләү – 1 сәг.
- Дәрес-диспут :”Туфан Миңнуллинның “Эзләдем, бәгърем, сине” драмасы һәм бүгенге тормыш”– 1 сәгать.
- А.Гыйләҗевнең “Өч аршын җир” әсәренә рецензия язу – 1 сәгать.

**Календарь-тематик план**

| № | Дәрес темасы | Дәресне үткәрү вакыты | | Искәрмә |
|---|---|---|---|---|
| | | планлаштырылган | фактик | |
| | **Сугыш чоры мәдәниятеһәм әдәбияты (12 сәгать)** | | | |
| 1 | Татарская литература первой половины XX века/Сугыш чоры әдәбияты | | | |
| 2-3 | Жизнь и творчество М. Джалиля. Послевоенное и послевоенное творчество поэта/М.Җәлилнең тормыш һәм иҗат юлы. Шагыйрьнең сугыш чоры һәм тоткынлык иҗаты. “Моабит дәфтәрләре” циклы. Шигырьләре: “Хуш, акыллым”, “Окоптан хат”, “Кыз үлеме”, “Кичер, илем”. | | | |
| 4-5 | Выражение ненависти к врагу в стихах М. Джалиля./“Кошчык”, “Шагыйрь”, “Дару”, “Бүреләр”, “Төрмәдә төш” һ.б. шигырьләрендә дошманга нәфрәтнең чагылышы. “Моабит дәфтәрләре”ндәге юмор үзенчәлеге. | | | |
| 6 | Упражнения по художественному пересказу произведений различных жанров./ Төрле жанрдагы әсәрләрне сәнгатле сөйләргә өйрәнү күнегүләре. М.Җәлилнең “Кичер, илем” шигырен сәнгатьле итеп яттан сөйләү. | | | |
| 7-8 | Теория литературы. Особенности косной и косной речи. Ритм и рифма, строфа, строфа./ Әдәбият теориясе. Тезмә һәм чәчмә сөйләм үзенчәлекләре. Ритм һәм рифма, тезмә, строфа.**Ф.Кәрим**нең сугыш чоры шигърияте. “Шомырт куагы”, “Кала яшьлек”, “Кайгы” шигырьләре. | | | |
| 9 | **БСТҮ Сочинение: “**Билгеләми гомер озынлыгын Еллар саны, картлык җитүе”.(М.Җәлил) | | | |
| 10 | **Ә. Еники**. Тәрҗемәи хәле һәм иҗаты белән таныштыру. “Ана һәм кыз”, “Бер генә сәгатькә” хикәяләрендә сугыш авырлыклары чагылу. | | | |
| 11 | Ф.Хусни Перстень/**Ф.Хөсни**нең тормыш һәм иҗат юлы. “Йөзек | | | |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | кашы” повестенда лирик якты хисләрнең тасвирлануы, мәхәббәтнең үкенечле соңы. | | | |
| 12 | Ф.Хусни Перстень/ “Йөзек кашы” әсәрендә Айдар холкының үзенчәлекләре. <u>Әдәбият теориясе.</u>Язучы стиле: көлке, тәнкыйди, фаҗигале, экзистенциаль, публицистик һ.б. башлангычлар. | | | |
| **Сугыштан соңгы чор мәдәниятеһәм әдәбияты(1950–1960нчы еллар) ( 7 сәгать)** | | | | |
| 13 | Особенности литературы 1950-х-1960-х годов/ 1950-1960нчы еллар әдәбиятына хас үзенчәлекләр. XX гасырның икенче яртысында “Хрущев җепшеклеге” исемен алган ярымдемократик үзгәрешләрнең сүз сәнгатенә уңай йогынтысы. | | | |
| 14 | В творчестве Х. Туфана заключительного периода получили новые оттенки чувства печали, печали, трагедии./ **Х.Туфан**ның тоткынлык чор иҗатында моң-зар, хәсрәт-сагыну, фаҗига хисләренең яңа төсмерләр алуы. “Ә үткәнгә хатлар бармыйлар”, “Иртә төшкән кар”, “Иртәләр җитте исә” шигырьләре. <u>Әдәбият теориясе.</u> Әдәби алымнар: кабатлау, янәшәлек, каршы кую, үткәнгә әйләнеп кайту (ретроспекция). | | | |
| 15 | . Новшество, принесенное автором в татарскую поэзию./Авторның татар шигырь төзелешенә алып килгән яңалыгы. “Агыла да болыт агыла”, “Сиңа” шигырьләрен уку, анализлау.<u>Әдәбият теориясе.</u>Тел–стиль чаралары (лексик, стилистик, фонетик чаралар һәм троплар). | | | |
| 16-17 | Жизнь и творчество Х. Вахита./**Х.Вахит**ның тормыш юлы һәм иҗаты. “Беренче мәхәббәт” драмасын өйрәнү. “Беренче мәхәббәт” драмасында гаилә һәм мәхәббәт өчен җаваплылык мәсьәләләренең үзенчәлекле бирелеше. | | | |
| 18-19 | **БСТҮ Контроль сочинение:** “Мәхәббәт, ул үзе иске нәрсә…” (Һади Такташ) | | | |
| Культура и литература 1960–х-80-х годов/ **1960–80нче еллар мәдәнияте һәм әдәбияты ( 31 сәгать)** | | | | |
| 20 | Возвращение татарской литературы к национальным истокам. В этот период появляются новые жанры, темы, мотивы, литературные формы./ Татар әдәбиятының милли нигезләргә кайтуы. Шушы чорда яңа жанрларның, тема-мотивлар, әдәби формаларның аваз салуы. Әдәбиятның яңалыкка омтылышы: яңа иҗади агымнарга, жанр формаларына, темаларга мөрәҗәгать итү, әдәби герой мәсьәләсендә | | | |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | эзләнүләр. | | | |
| 21 | Возрождение традиций в литературе 1960-х-80-х годов, поиск новых общественных качеств, нового героя./1960–80нче еллар әдәбиятында традицияләрнең яңаруы, яңа җәмгыять сыйфатларын эзләү, яңа герой. «Авыл прозасы». Ватан, ил, халык образларының эпик гәүдәләнеше; шәхес һәм җәмгыять мөнәсәбәтләре, гражданлык хисе, халыклар язмышы, кешенең рухи дөньясы, чор кыйммәтләре турында уйлану. Азатлык, шәхес иреге, фикер хөрлеге мәсьәләләренең куелышы. | | | |
| 22 | Возрождение направления романтизма. Революция 1917 года изменила отношение к вновь созданной жизни. Постановка темы войны в другой плоскости./ Романтизм юнәлешенең яңадан тергезелүе. 1917 еллар инкыйлабына, яңадан төзелгән тормышка бәянең үзгәреш кичерүе. Сугыш темасының үзгә яссылыкта куелышы. | | | |
| 23 | Жизнь и творчество Амирхана Еники./ **Әмирхан Еники**нең тормыш юлы, иҗаты. “Төнге тамчылар” хикәясендә психологик анализ алымнары. <u>Әдәбият теориясе.</u> Әсәрдә сурәтләнгән дөнья. Пейзаж, портрет. Психологизм. | | | |
| 24-25 | Внеклассное обучение./ **Дәрестән тыш уку.** Ә.Еники. “Гөләндәм туташ хатирәсе” әсәрендә яшьләр арасындагы матур мөнәсәбәтләр, киләчәгең өчен җаваплылык мәсьәләләре. | | | |
| 26 | Жизнь и творчество М.Магдиева/ **Мөхәммәт Мәһдиевнең** тормыш һәм иҗат юлы. Әсәрләрендә сугыш алды, сугыш һәм сугыштан соңгы елларда татар авылы тормышы чагылу. “Кеше китә - җыры кала” повесте. | | | |
| 27 | Особенности описания образа жизни нашего народа в произведении М. Магдеева “Человек уходит - песня остается”./ М.Мәһдиевнең “Кеше китә - җыры кала” әсәрендә халкыбызның яшәү рәвешен сурәтләү үзенчәлекләре. <u>Әдәбият теориясе.</u> Әдәбиятның иҗтимагый вазифасы турында белемнәрне ныгыту. | | | |
| 28 | Внеклассное обучение.Повесть М. Магдеева “Там, где падают журавли”./ **Дәрестән тыш уку.** М.Мәһдиевнең “Торналар төшкән җирдә” повесте. | | | |
| 29-30 | **БСТҮ Сочинение:** М. Магдеев – поэт, воспевающий славу татарской деревни". / “М.Мәһдиев – татар авылына дан җырлаучы әдип”. | | | |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| 31-32 | Жизнь и творчество С.Хакима / **С.Хәким**нең тормыш юлы, иҗаты. “Башка берни дә кирәкми”, “Сусау” шигырьләрен уку һәм анализлау. Әдәбият теориясе. Шигырь төзелеше. | | | |
| 33 | **Жизнь и творчество А.Гилязова /Аяз Гыйләҗев** иҗатына күзәтү. Кеше һәм җәмгыять мөнәсәбәтләрен тасвирлауда язучы иҗатында үсеш-үзгәрешләр. “Өч аршын җир” повестенда Мирвәли язмышы. Әдәбият теориясе. Әдәби әсәрдә урын һәм вакыт, хронотоп. | | | |
| 34-35 | **БСТҮ** Рецензия на произведение А. Гилязева “три аршина земли”. А.Гыйләҗевнең “Өч аршын җир” әсәренә рецензия язу. | | | |
| 36-38 | Внеклассное обучение. Повесть А. Гилязева. Особенности создания образов и характеров в произведении/ **Дәрестән тыш уку.** А.Гыйләҗевнең “Әтәч менгән читәнгә” повесте. Әсәрдә образ-характерлар иҗат итү үзенчәлекләре. Әдәбият теориясе. Композиция: тышкы һәм эчке корылыш. | | | |
| 39-40 | Обзор творчества Гарифа Ахунова. В романе ”Дочь Волги " - вопрос о революции и судьбе личности./ **Гариф Ахунов**иҗатына күзәтү ясау. “Идел кызы” романында инкыйлаб һәм шәхес язмышы мәсьәләсе. | | | |
| 41-42 | В романе «Дочь Идел» богат и противоречивый духовный мир Аббаса муллы. “Идел кызы” романында Габбас мулланың бай һәм каршылыклы рухи дөньясы. Әдәбият теориясе. Тема, проблема, идея, пафос. Идеал. | | | |
| 43-44 | Описание человека и природы в поэме Ахсана Баянова “Шахнаме” с философской глубиной./ **Әхсән Баянов**ның “Сәяхәтнамә” поэмасында кеше һәм табигатьне фәлсәфи тирәнлек белән сурәтләү. Әдәбият теориясе. Лиро-эпик жанрлар: сюжетлы шигырь, мәсәл, баллада, нәсер, поэма.Поэма жанрының төрләре: романтик поэма, реалистик поэма. Төрара формалар: сәяхәтнамә. | | | |
| 45 | Подготовка к написанию сочинения: составление плана, подбор эпиграфа, сбор материала./ Сочинение язуга әзерлек: план төзү, эпиграф сайлау, материал туплау. | | | |
| 46-47 | **БСТҮ Сочинение:** “Их, яшисе иде озак, мәңге…Табигатьтән башка үле без...” (И.Юзеев) | | | |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| 48-50 | **Внеклассное чтение / Дәрестән тыш уку.** Әхсән Баянов. “Тау ягы повесте”. Әдәбият теориясе. Эпиграф, багышлау, көчле позиция. | | | |
| **1980–2000нче еллар мәдәнияте һәм әдәбияты ( 38 сәгать)** | | | | |
| 51 | На рубеже XX-XXI веков татарская литература еще раз преобразилась, поднялась новой волной./ XX-XXI гасыр чигендә татар әдәбиятының тагын бер тапкыр үзгәрүе, яңа дулкын булып күтәрелүе. Үзгәрешләрнең XX гасыр башы татар әдәбиятындагы эзләнүләргә аваздаш булуы. Реализмның типиклаштыруны иҗтимагый–сыйнфый баскычтан гомумкешелек югарылыгына күтәрүе. | | | |
| 52 | В 1980-е-2000-е годы писал произведения, критически оценивающие советское и постсоветское время, рисующие противостояние личности и общества, большие этапы в истории страны./ 1980–2000нче елларда Совет һәм постсовет заманына тәнкыйди бәя биргән, шәхес һәм җәмгыять каршылыгы ноктасыннан, ил тарихындагы олы этапларның сурәтен тудырган әсәрләр язылу. | | | |
| 53-54 | Роман И. Салахова “Колымские рассказы” (отрывки). Значение романа как произведения, во всей полноте показывающего трагедию культа личности, принесенную народу./ **И.Салахов**ның “Колыма хикәяләре” романы (өзекләр). Романның шәхес культының халыкка алып килгән фаҗигасен бөтен тулылыгы белән күрсәткән әсәр буларак әһәмияте. | | | |
| 55-56 | Особенности описания душевного мира женщины в повести” бескрылые лебеди", психологизм произведения Ф. Байрамовой./ .**Ф.Бәйрәмова**ның тормыш һәм иҗат юлы. “Канатсыз акчарлаклар” повестенда хатын-кызның күңел дөньясын сурәтләү үзенчәлекләре, әсәрнең психологизмы. | | | |
| 57-58 | Справка о жизни и творчестве Н. Гиматдиновой. Анализ повести «Колдун». Новизна произведения в татарской литературе. Теория литературы. Мифологический образ, архетип./ Н.Гыйматдинованың тормыш юлы һәм иҗаты турында белешмә. “Сихерче”повестена анализ. Әсәрнең татар әдәбиятына алып килгән яңалыгы. Әдәбият теориясе. Мифологик образ, архетип. | | | |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| 59-60 | **Внеклассное чтение/ Дәрестән тыш уку.** Р.Мөхәммәдиев. “Ак кыялар турында хыял”. Әдәбият теориясе. Лирик чигенешләр. Сәнгатьчә дөреслек категориясе. | | | |
| 61-62 | В романе М. Хабибуллина “Кубрат хан” (отрывки) внимание к общечеловеческим ценностям, их рассмотрение в свете интересов страны./ **М.Хәбибуллин**ның “Кубрат хан” романында (өзекләр) гомумкешелек кыйммәтләренә игътибар, аларны ил мәнфәгатьләре яктылыгында карау. | | | |
| 63-64 | Жизнь и творчество Туфана Миннуллина. Роль драматургии Т. Миннуллина в развитии татарского театрального искусства./ **Туфан Миңнуллин**ның тормыш юлы, иҗаты. Татар театр сәнгатен үстерүдә Т.Миңнуллин драматургиясенең роле. “Эзләдем, бәгърем, сине” драмасында рухи ныклык, үз бәхетең өчен көрәшүнең әһәмиятен күрсәтү. | | | |
| 65 | Урок-диспут: “Туфан Минуллина” искала, Ищу, тебя " драма и современная жизнь / Дәрес-диспут: “Туфан Миңнуллинның “Эзләдем, бәгърем, сине” драмасы һәм бүгенге тормыш. Әдәбият теориясе. Әдәби сөйләм: хикәяләү, сөйләшү (диалог), сөйләү (монолог). | | | |
| 66-68 | **Внеклассное чтение/ Дәрестән тыш уку.** Т.Миңнуллинның “Саташу” драмасы. | | | |
| 69-70 | И. Юзеева. Драма” Гора влюбленных " – произведение, построенное на романтической любовной трагедии./ **И.Юзеев**ның тормыш һәм иҗат юлы. “Гашыйклар тавы” драмасы – романтик мәхәббәт фаҗигасенә корылган әсәр. | | | |
| 71 | В произведении ” Гора влюбленных " проблемы человека и природы, любви и предательства./ “Гашыйклар тавы” әсәрендә кеше һәм табигать, мәхәббәт һәм хыянәт проблемалары. | | | |
| 72-73 | Сочинение: “И.Юзеев иҗатында кеше һәм табигать мөнәсәбәтләренең чагылышы.” | | | |
| 74-76 | **Внеклассное чтение/ Дәрестән тыш уку.** Р.Батулла. “Кичер мине, әнкәй” мелодрамасы. | | | |
| 77-78 | Современная татарская поэзия, приход новых творческих сил, новые темы и идеи. Обзор творчества Р. Файзуллина./ Хәзерге татар поэзиясе, яңа иҗат көчләренең килүе, яңа тема һәм идеяләр. **Р.Фәйзуллинның** иҗатына күзәтү. “Нюанслар илендә” циклына керүче шигырьләрен уку һәм анализлау. | | | |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| 79-80 | Жизнь и творчество Р. Миннуллина **/ Р.Миңнуллин**ның тормыш юлы һәм иҗаты. “Татарларым” поэмасында татарның бөек үткәне белән горурлану, бүгенге асылын ачып бирергә тырышу. | | | |
| 81-82 | **Г.Афзал / Гамил Афзал**ның “Язмышлар”, “Чабаклар йөзгән Иделдә”, “Елмаям уйчан гына”, “Бигрәк юаш басып йөрдем җиргә” шигырьләре. Әдәбият теориясе. Көлке: юмор, сатира, сарказм, шарж. | | | |
| 83-84 | Природа поэзии М. Аглямова./ **М.Әгъләмов** шигъриятенең табигыйлеге. “Кичер!”, “Дәвам” шигырьләренең фикри һәм сәнгатьчә яңалыгы. | | | |
| 85-86 | Природа поэзии М. Аглямова./ **М.Әгъләмов** шигъриятенең табигыйлеге. “Кичер!”, “Дәвам” шигырьләренең фикри һәм сәнгатьчә яңалыгы. | | | |
| 87-88 | В поэзии Р.Хариса дух современности, стремление к глубине мысли. Чтение и анализ поэмы "Сны любви Тукая"./**Р.Харис** поэзиясендә заманчалык рухы, фикер тирәнлегенә омтылыш. “Тукайның мәхәббәт төшләре” поэмасын уку һәм анализлау. | | | |
| **2000—2010нчы еллар мәдәнияте һәм әдәбияты ( 10 сәгать )** | | | | |
| 89 | Обзор литературы 2000-2010-х годов. Через выдвижение психологического начала в жизнь личности, утверждение ее внутреннего мира над историко–общественной действительностью. Восстановление процессов, происходящих в сознании человека, в корне его сознания. /2000 – 2010нчы еллар әдәбиятына күзәтү. Психологик башлангычның алга чыгуы аша шәхес тормышы, эчке дөньясының тарихи–иҗтимагый чынбарлыктан өстен булуын раслау. Кешенең аңында, аң төпкелендә барган процессларны тергезү. | | | |
| 90 | С помощью активизации мифологических, условно–символических образов поставить национальную проблематику в новой плоскости, поднять национализм как силу, противостоящую тоталитарной идеологии. /Мифологик, шартлы–символик образларның активлашуы ярдәмендә милли проблематиканы яңа яссылыкта кую, миллилекне тоталитар идеологиягә каршы торучы көч итеп күтәрү. | | | |
| 91-92 | Обзор жизни и творчества М. Кабирова. Чтение и анализ повести ” Песни о любви". /**М. Кәбиров**ның тормыш юлы һәм иҗатына күзәтү. “Мәхәббәттән җырлар кала” повестен уку һәм анализлау. | | | |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| 93 | Идейно-эстетическое содержание повести М. Кабирова “От любви остаются песни”. /М. Кәбировның “Мәхәббәттән җырлар кала” повестеның идея-эстетик эчтәлеге. | | | |
| 94-95 | Творчество Р. Зайдуллы-поэзия с философско-публицистическим звучанием. Стихи ”Мы готовились к полету“, ”Опоздание“, ”Метель", их отличительные черты./ **Р. Зәйдулла**ның иҗаты - фәлсәфи-публицистик яңгырашлы шигърият. “Без очарга әзерләнгән идек”, “Соңару”, “Буран” шигырьләре, аларның үзенчәлекле яклары. | | | |
| 96-97 | Обзор жизни и творчества Зульфата Хакимова. Драма ”Мелодия века"./ **Зөлфәт Хәким**нең тормыш юлы һәм иҗатына күзәтү. “Гасыр моңы” драмасы. | | | |
| 98 | Идейно-проблематика, система образов драмы Зульфата Хакимова “Мелодия века”./ Зөлфәт Хәкимнең “Гасыр моңы” драмасының идея-проблематикасы, образлар системасы. | | | |
| **Дөнья әдәбиятының барышы. Татар, рус һәм чит ил әдәбиятлары арасында күптөрле бәйләнешләр. Әдәби тәнкыйть ( 3 сәгать)** | | | | |
| 99 | Ход мировой литературы. Многообразие связей между татарской, русской и зарубежной литературой. Вечные темы и образы./ Дөнья әдәбиятының барышы. Татар, рус һәм чит ил әдәбиятлары арасында күптөрле бәйләнешләр. Мәңгелек темалар һәм образлар. | | | |
| 100 | Татарская детская литература. Критика как спутник литературного процесса/ Татар балалар әдәбияты. Әдәби процессның юлдашы буларак тәнкыйть. | | | |
| **Татар әдәбиятыннан белем сыйфатын тикшерү. Йомгак.** | | | | |
| 101 | Промежуточная аттеационная работа/ Тест формасында йомгаклау контроль эше. | | | |
| 102 | Подведение итогов тестирования. Путь, который прошла татарская литература. /Тестларга нәтиҗә ясау. Татар әдәбияты узган юл. | | | |

**Укучыларның белем дәрәҗәсенә таләпләр**

**11 нче сыйныф укучылары белергә тиеш:**

- милли әдәбиятның иң билгеле язучыларын һәм аларның әсәрләре хакында;

- милли әдәбиятның нинди чорларга бүленешен;
- сүз сәнгатенең образлы асылын;
- әдәби-тарихи барышның төп закончалыкларын һәм әдәби юнәлеш, күренешләрнең төп сыйфатларын;
- төр әдәби-теоретик төшенчәләрне.

**11 нче сыйныф укучылары ия булырга тиешле күнекмәләр:**

- әдәби әсәр эчтәлеген кабатлап сөйләү;
- әдәби әсәрне әдәбият тарихыннан һәм теориясеннән мәгълүматлар файдаланып анализлау;
- әдәби әсәрнең, язучы иҗатының, чор әдәбиятының аерым якларын, элементларын җентекләп тикшерү һәм нәтиҗәләр чыгару;
- әдәби әсәрне, язучы иҗатын, чор әдәбиятын иҗтимагый-тарихи контекстта һәм гомумкешелек кыйммәтләре яктылыгында бәяләү;
- әдәби әсәрнең төр һәм жанрын, кайсы чорда язылуын билгеләү, чор әдәбиятына хас сыйфатларны табу;
- бер чорда иҗат ителгән һәм төрле чорларда иҗат ителгән әдәби әсәрләрне чагыштыру;
- әдәби әсәргә карата дәлилле шәхсән мөнәсәбәт белдерә алу;
- әдәби әсәрләр хакында төрле характердагы иҗади эшләр башкару.

**Интернет-ресурс материалларын файдалану**

1. ТР Мәгариф һәм фән министрлыгы сайты:  http://www.mon.tatar.ru
2. “Татар әдипләре” сайты: http://adiplar.narod.ru/minnullin_tufan.htm
3. “Кем ул Заһир Бигиев?” сайты:http://zahirbigiyev.blogspot.com/
4. “Мифтахетдин Акмулла” сайты: http://www.akmulla.ru/
5. Шигъри әсәрләрнең аудиоязмалары: http://miras.belem.ru/node/475
6. “Таткнигафонд.ru” электрон китапханәсе: http://www.tatknigafund.ru
7. “Белем. ru” порталы: http://www.belem.ru
8. http://gzalilova.narod.ru/index.html
9. Электрон китапханә: http://kitap.net.ru/husni
10. “Китапханә. Татарстан” электрон китапханәсе: kitaphane.tatarstan.ru